Статистика мәгълүмат-ларына караганда, янгын очракларынын күпчелеге торак һәм производство секторларында була. Топ бәла - гражданнарнын, бигрәк тә эчкечеләрнен, ут белән саксыз куллануы, электр жиһазлары һәм конкүреш приборлары белән файдаланганда янгын хәвефсезлеге кагыйдәләрен бозу.

Яз житү белән иске үлән, тирә-якны жыештырганнан сон барлыкка килгән чүпне яндыру гадәткә кергән. «Кызыл әтәч» куркыныч житезлек белән бина стеналары буйлап үрмәләгән минутларда кешеләр «01» санлы телефонга шалтырата. Мордовиянен әле бер почмагында, әле икенчесендә янгын чыкканы турында хәбәрләрне янгын сундеручеләр ишеттереп тора. Тарих битләренә күз салыйк. 1649 елнын 30 апрелендә рус патшасы Алексей Михайлович рус дәүләтендә беренче тапкыр төүлек әйләнәсенә янгын сундеручеләр кизүен (караулын) оештыру турында документка кул куя. Кизү торган кешеләр янгын хәвефсезлеге кагыйдәләре үтәлүне дә тикшерергә тиеш булалар. Кагыйдә бозучыларны җәзага тарттыру хокуклары да була аларнын.

Октябрь революциясеннән сон ярты ел үткәч, 1918 елнын 17 апрелендә Владимир Ленин «Ут белән корәш чараларын оештыру турында»гы декретка кул куя. Бу кон СССРда 70 ел буена «Янгын сундеручеләр коне» буларак билгеләнә.

Беренче янгын сундеручеләр отрядларын оештыруга 350 ел үткәч, Россиянен беренче президенты Борис Ельцин тарафыннан 30 апрель янгын саклау хезмәткәрләренен һонәри бәйрәме итеп игълан ителә.

Бүген янгынга каршы дәүләт хезмәте - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы составындагы квалификацияле кадрлары, заман техникасы, фәнни һәм укыту базалары булган кочле оператив хезмәт. Бәйрәм кысаларында регионыбыз буенча, янгын сундеручеләргә багышлап, торле чаралар үтте. Шулай, Мордовия буенча Россия ГУ МЧС бүлеге «Ин әйбәт профессиональ мастер - Лучший по профессиональному мастерству» конкурсы игълан итте. Берничә номинация буенча ярышканнар: янгын сундерүче, караул начальнигы, бүлек командиры, янгын сундерүче машина йөртүче, диспетчер һәм надзор эше буенча инспектор. МЧС хезмәткәрләре дүртенче этаж тәрәзәсенә штурм баскычы буенча менү, коткару тоеннәрен (узлов) бәйләү, челночный йогерү, турникта күтәрелү кебек сынаулар үткән. Конкурсантлар шулай ук янгын сундерү теориясе буенча да белемнәрен сынадылар.

Ярыш нәтиҗәләре буенча, жи-нүчеләр арасында Темник район-нынын ин әйбәт хезмәткәре, татар милләтле Артур Радий улы Абушкин (пожарный ПСЧ-3) булды. Рәсемдәге Темник районы янгын сундеручеләренен татар милләтле караул нәчәлнекләре - Р. М.Тугушев, С.В.Гараев, А.И.Емашев, тагы рус милләтле А.А.Конкин

хезмәтләрен жиренә житкереп башкаралар. Бурычларына тугры алар.

Н.Хәлил